МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.11.2019 г.Казань № 1037

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 17 декабрендә 6073 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 16 октябрендәге 950 номерлы, 2019 елның 7 маендагы 331 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен,

эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 16 ноябрендәге 1037 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3 пунктта «Дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар (гариза бирүчеләр)» сүзләрен «Гариза бирүчеләр» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте, халыкның мәшгульлек үзәге урнашкан урын, аның эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (алга таба – Татарстан Республикасы порталы) урнаштырылган.»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелде.»;

1.7 пунктта:

беренче абзацта «урнашу урыны турында» сүзләреннән соң «белешмә телефоннары, электрон почта адресы» сүзләрен өстәргә;

1 пунктчада «әлеге Административ регламентның 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында булган» сүзләрен «әлеге Административ регламентның 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында булган» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Күченгәндә эшсез гражданнарга һәм Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнаштыру өчен башка җирлеккә күчерелгәндә эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү | Халык мәшгульлеге турында законның 7.1-1 статьясының 1 пунктындагы 8 пунктчасы |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы Халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениесе (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге).<br>Халыкның мәшгульлек үзәге Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлеге территориясендә дәүләт хезмәте күрсәтелүен гамәлгә ашыра | 92н номерлы стандартның 4 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:<br>эшсез гражданинга 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкның 7 нче кушымтасына ярашлы форма буенча башка җирлектә эшкә урнашу өчен юллама бирү;<br>күченгәндә эшсез гражданинга яки халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченеп урнашканда эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме күрсәтү яки аны күрсәтүдән нигезләнгән рәвештә баш тарту;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар | 92н номерлы стандартның 20 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша | Эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган срогы 30 минуттан артып китәргә тиеш түгел, күченү турында шартнамә (күченеп урнашу турында шартнамә) | 92н номерлы стандартның 19 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | төзү өчен, шулай ук эшсез гражданинга (эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына) финанс ярдәме күләмен билгеләү һәм аны банкта яки башка төрле кредит оешмасында ачтырылган шәхси счетка (исәп-хисап счетына) күчерү өчен кирәкле вакыттан тыш.<br>Инвалидлар категориясенә караучы эшсез гражданнарга дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы, үз инициативасы белән инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын (алга таба – хосусый программа) яки медик-социаль экспертиза (алга таба – МСЭ) буенча федераль учреждениедән билгеләнгән тәртиптә бирелгән хосусый программа өземтәсе (инвалидлар категориясенә караучы гражданнар өчен) тапшырылмаган очракта, һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программа өземтәсе булмаганда, гаризаны теркәгән датадан башлап 7 эш көне тәшкил итә.<br>Эшсез гражданинга финанс ярдәме билгеләнгәндә, финанс чаралары Халыкның мәшгульлек үзәге счетына акча күчкән көннән башлап календарь көннәрендә исәпләнә торган 7 көнлек срокта 515 номерлы тәртиптә һәм төзелгән килешүдә каралган шартлар нигезендә эшсез гражданин тарафыннан күрсәтелгән шәхси счетка (исәп-хисап счетына) күчерелә.<br>Эшсез гражданин белән халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү датасын һәм вакытын килештерү, «Интернет» челтәрен дә кертеп, телефон яки электрон элемтә чараларыннан, почта элемтәсеннән файдаланып, гаризаны теркәгән көннән соң килгән эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Эшсез гражданинның мөрәҗәгать итү датасы һәм вакыты алдан килешенгән очракта дәүләт хезмәтен күрсәтүне көтү вакыты 5 | 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерыкка 3 нче кушымтаның 1 пункты<br>515 номерлы тәртипнең 3.3 пункты<br>92н номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| | минуттан артып китәргә тиеш түгел.<br>Эшсез гражданин КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, КФҮ белән халыкның мәшгульлек үзәге арасында төзелгән хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән срокларда, ләкин гаризаны теркәгән көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмыйча, гаризаның халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырылуы тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралмаган | стандартның 8 пункты<br><br><br><br><br><br>92н номерлы стандартның 9 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Халыкка эшкә урнашуда булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 13 нче кушымтага туры китерелгән формалы гариза (алга таба – гариза) яки халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан бирелгән халыкны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 14 нче кушымтага туры китерелгән формалы тәкъдим (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме) һәм дәүләт хезмәте алучының халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдименә ризалыгы.<br>2. Эшсез гражданин мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклаучы документ (Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документны; чит ил гражданинының, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документны) күрсәтә.<br>3. Гаилә әгъзалары булган эшсез гражданин эшкә урнашу өчен башка җирлеккә яңа яшәү урынына күченеп урнашуда ярдәм буенча дәүләт хезмәтен алу өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне | 92н номерлы стандартның 5 пункты<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>92н номерлы стандартның 14 пункты<br>92н номерлы стандартның 15 пункты<br><br><br><br><br>92н номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшыра:<br>үзенең гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның (чит ил гражданинының шәхесен һәм таныклыгын таныклаучы документлар, - чит ил гражданины булган гаилә әгъзасы өчен, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ, - гражданлыгы булмаган зат булып торучы гаилә әгъзасы өчен) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләрен;<br>эшсез гражданинның гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгеләрне раслаучы документ (документлар):<br>аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуын;<br>эшсез гражданинның персональ белешмәләрне халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырганда алар исеменнән эш йөртүгә вәкаләтле булуын.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм халыкның мәшгуль үзәге белгече тарафыннан таныклана.<br>4. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан финанс ярдәмен билгеләү һәм халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә вакытлыча эшкә урнашу өчен күченгәндә (яңа яшәү урынына күченеп урнашканда) эшсез гражданинга күчерү турында карарны кабул итү өчен эшсез гражданин 515 номерлы тәртипкә 1-4 нче кушымталарга туры китерелгән форма буенча гариза тапшыра, түбәндәге документларны теркәп:<br>вакытлыча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә: | стандартның 15 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | эшкә алучы белән төзелгән, билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе законнарына туры китереп эшкә алучы тарафыннан таныкланган хезмәт шартнамәсенең күчермәсен;<br>Россия Федерациясе законнарына туры китереп эшкә алучы тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсен (төп нөсхәсе тапшырылмаган очракта), эшкә алу (хезмәт шартнамәсенең яки күченү турында шартнамә срогы узуга бәйле рәвештә эштән китү) турында язуы белән;<br>515 номерлы тәртипнең 2.1.2.1 һәм 2.1.2.2-пунктларында каралган чыгымнар турындагы белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләрен (515 номерлы тәртипнең әлеге пунктларында каралган чыгымнарны компенсацияләү очрагында);<br>515 номерлы тәртипнең 2.1.2 пункты нигезендә компенсацияләнергә-тиешле чыгымнар турында белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләрен (515 номерлы тәртипнең 2.1.5 пункты нигезендә элегрәк өлешчә компенсацияләү очрагында);<br>515 номерлы тәртипнең 2.1.2 пункты нигезендә компенсацияләнергә тиешле чыгымнар турында белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләрен (515 номерлы Тәртипнең 2.1.5 һәм 2.1.6 пунктлары нигезендә элегрәк компенсация гамәлгә ашырылмаган очракта);<br>банкта яки башка кредит оешмасында ачтырылган шәхси счет (исәп-хисап счеты) күчермәсен;<br>эшкә урнашу өчен башка җирлеккә яңа яшәү урынына күченеп урнашканда:<br>эшкә алучы белән төзелгән, Россия Федерациясе законнарына туры китереп эшкә алучы тарафыннан таныкланган хезмәт | 515 номерлы тәртипнең 2.1.5 пункты<br>515 номерлы тәртипнең 2.1.6 пункты<br>515 номерлы тәртипнең 2.1.7 пункты<br>515 номерлы тәртипнең 2.1.5 пункты<br>515 номерлы тәртипнең 2.1.6 пункты<br>515 номерлы тәртипнең 2.1.7 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | шартнамәсенең күчермәсен;<br>Россия Федерациясе законнары нигезендә эшкә алучы тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсен (төп нөсхәсе тапшырылмаган очракта), эшкә алу турында язуы белән;<br>эшсез гражданинның һәм аның гаилә әгъзаларының күченеп урнашу буенча транспорт чыгымнары, яңа яшәү урынына барган вакытта тәүлеклек чыгымнары һәм элеккеге яшәү урыныннан яңа яшәү урынына йорт мөлкәтен алып бару бәясен түләү чыгымнары (шартнамәләр, башкарылган эшләр актлары, исәп-хисап-фактуралары, квитанцияләр, касса чеклары һ.б.) турында белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләре;<br>эшсез гражданинның шәхесен таныклаучы документ күчермәсен;<br>эшсез гражданинның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның күчермәләрен;<br>гаилә әгъзаларының персональ белешмәләрен тапшырганда эшсез гражданинның гаилә әгъзалары исеменнән яки аларның законлы вәкилләре исеменнән эш итүгә вәкаләтле булуын раслаучы документны;<br>банкта яки башка кредит оешмасында ачтырылган шәхси счет (исәп-хисап счеты) күчермәсен.<br>Гариза эшсез гражданинның шәхси яки 63-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гади электрон имзасы белән таныклана.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре, паспорт күчермәсен яисә аны алмаштыра торган документ күчермәсен дә кертеп, Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш. | 515 номерлы тәртипнең 2.2.5 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза бирүче вәкиле өстәмә рәвештә гариза бирүченең мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен тапшыра.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза кәгазен эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар эшсез гражданин тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә эшсез гражданин исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>почта аша.<br>Гариза белән аңа теркәлә торган документлар шулай ук эшсез гражданин тарафыннан гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм халыкның мәшгуль үзәге белгече тарафыннан таныклана | 92н номерлы стандартның 5 пункты |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:<br>14 яше тулмаган эшсез гражданның гаилә әгъзаларының тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (алга таба – туу турында таныклык)) (ГХАТ органнарында); | 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында) (алга таба – өйләнешү турында таныклык);<br>гаилә составы турында белешмәләр (гражданнарның тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәү исәбенә алуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле оешмаларда);<br>хосусый программадан өземтә, түбәндәгеләрне үз эченә ала:<br>эшкә урнаштыру һәм хезмәт шартлары буенча киңәшләр (мөмкин булган эш төрләре һәм башкарылуы кыен булган хезмәт гамәлләре (функцияләр);<br>организмның бозылган функцияләрен һәм яшәеш эшчәнлегендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидның киңәш ителә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлек төрләрен сайлау өчен белешмәләр.<br>Әлеге белешмәләр аларны МСЭ буенча федераль учреждение мөстәкыйль җибәрмәгән очракта, 486 н номерлы боерыкка 1 нче кушымтаның 14 пунктындагы «д» пунктчасы нигезендә соратыла.<br>Эшсез гражданин шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән мөмкинлек булганда электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Эшсез гражданин тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Халыкның мәшгульлек үзәге эшсез гражданиннан түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган | |

| | | |
|---|---|---|
| | мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган. | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашуга ярдәм итү өлешендә эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>1) әлеге Административ регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе;<br>2) түбәндәгеләрнең булмавы:<br>- гариза яки эшсез гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турында халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме белән ризалыгы;<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алмаштыра торган документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документлар (чит ил гражданнары өчен);<br>- гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документлар (гражданлыгы булмаган затлар өчен);<br>- инвалидны тернәкләндерүнең хосусый программасы яисә билгеләнгән тәртиптә бирелә торган (инвалидлар категориясенә керә торган гражданнар өчен) инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасы);<br>3) гариза теркәлә торган документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган килеш почта аша килүе.<br>Халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен эшсез гражданинга башка җирлеккә күченеп урнашуда ярдәм итү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>1) әлеге Административ регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе;<br>2) түбәндәгеләрнең булмавы: | 92н номерлы стандартның 11 пункты<br>92н номерлы стандартның 14 пункты<br>92н номерлы стандартның 15 пункты<br>515 номерлы тәртипнең 2.1.5, 2.1.6, 2.1.7, 2.2.5 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | - гариза яки эшсез гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турында халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме белән ризалыгы;<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алмаштыра торган документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документлар (чит ил гражданнары өчен);<br>- гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документлар (гражданлыгы булмаган затлар өчен);<br>- инвалидны тернәкләндерүнең хосусый программасы һәм билгеләнгән тәртиптә бирелә торган (инвалидлар категориясенә керә торган гражданнар өчен) инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасы);<br>- эшсез гражданинның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документлар (чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын раслаучы документлар, – гариза бирүченең чит ил гражданины булып торган гаилә әгъзасы өчен);<br>- гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документ, – гариза бирүченең гражданлыгы булмаган гаилә әгъзасы өчен;<br>3) гариза теркәлә торган документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган килеш почта аша килүе.<br>Халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашканда яки башка җиргә күчкәндә эшсез гражданинга финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып күчеп китү турында килешүнең яисә башка җирлеккә күчену турында килешүнең булмавы, агымдагы елның 25 декабренә кадәр 515 нче | |

| | | |
|---|---|---|
| | номерлы тәртипкә 1-4 нче кушымталар нигезендәге форма буенча гариза тапшырылмавы тора. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | 210-ФЗ номерлы федераль законның 8 ст.<br>1032-1 номерлы Халык мәшгульлеге турындагы законның 15 статьясының 3 пункты<br>92н номерлы стандартның 13 пункты |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү | Зарури һәм мәҗбүри документларны тапшыру таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхси мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәте чират тәртибендә күрсәтелә. Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать иткән очракта, чиратта максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Көне һәм вакыты алдан килештерелгән очракта, дәүләт хезмәтеннән файдалануны көтү вакыты 5 минуттан артмаска тиеш. | 92н номерлы стандартның 7 пункты 601 номерлы указның 1 пункты<br><br>92н номерлы стандартның 8 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза килгән вакыттан башлап бер көн эчендә.<br>Гаризаны теркәү дигәндә халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затларның (физик затларның һәм эшкә алучы затларның) электрон регистрына (алга таба – Дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар регистры), хисап язмасының теркәү номерын биреп, эшсез гражданин тапшырган документлардагы белешмәләрне кертү күз алдында тотыла.<br>Эшсез гражданинның мөрәҗәгате нигезендә гаризаны кабул итү көне һәм исәпкә алу язуының теркәлү номеры турында белешмәләр булган гариза күчермәсе бирелергә мөмкин.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | Халык мәшгульлеге турында законның 16.1 статьясындагы 2 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Эшсез гражданинга дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле булган мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда күрсәтелә.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү һәм чыгу өзлексез токның автоном чыганаклары белән тиешле күрсәткечләр белән җиһазландырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарда килүчеләргә файдалану мөмкинлеге булган иҗтимагый файдалану урыннарын (бәдрәфләрне) һәм өске кием-салымны саклау урыннарын булдыру күздә тотыла.<br>Халыкның мәшгульлек үзәге белгеченең эш урыны фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелгән дивар элмә тактасы һәм өстәл табличкасы белән җиһазландырыла. Халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелгән шәхси күкрәк тамгасы (бейдж) белән тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүмат хезмәттән файдаланучы затлар өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, шулай ук Интернет-ресурсларда да (Татарстан Республикасы порталында) урнаштырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында текстлы һәм мультимедиалы | 92н номерлы стандартның 10 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүматны рәсмиләштерү гражданнарның бу мәгълүматны оптималь күрү һәм ишетү ягыннан кабул итүенә туры килергә тиеш | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) | Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында мәгълүматның, хосусый яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү (шәхсән кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларыннан файдаланып, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару, мәгълүмат материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү, Татарстан Республикасы Порталында мәгълүмат урнаштыру юлы белән) формасында, эшсез гражданин тарафыннан файдалана алырлык булуы.<br>2. Эшсез гражданинның дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәк булган гаризалар һәм башка документлар формасына, шул исәптән аларны электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән керә алуын тәэмин итү.<br>3. Инвалидларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачау иткән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>4. Инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары белән расланган тәртипнең 2.4 пункты<br>601-номерлы указның 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15.1 статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге (шул исәптән тулы күләмдә) яки файдалана алмау | саклау.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән телефон элемтәсеннән, электрон почтадан файдаланып, Татарстан Республикасы порталы, КФҮ аша, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат-күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәгендә халык мәшгульлеге турында Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләрнең, әлеге Административ регламент нигезләмәләренең үтәлүе.<br>2. Дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын саклау.<br>3. Әлеге Административ регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеген саклау.<br>4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә баш тартуларның нигезле булуы.<br>5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезле шикаятьләрнең булмавы.<br>Эшсез гражданинның халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре белән үзара элемтәгә керү саны:<br>дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон документ формасында – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең халыкның | |

| | | |
|---|---|---|
| | мәшгульлек үзәге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте КФҮ аша, КФҮ читтән торып эшләү урыны аша күрсәтелми.<br>Эшсез гражданин КФҮ, КФҮ читтәге эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза КФҮдә теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибе - халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турында килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек итү тәртибе КФҮ эш регламенты белән җайга салына.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында эшсез гражданнарга Интернет челтәреннән файдаланып, эшкә алучы зат белән телефон аша яки видеоэлемтә ярдәмендә аралашу мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны эшсез гражданин Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы порталында алырга мөмкин | 92н номерлы стандартның 9 пункты<br><br>92н номерлы стандартның 23 пункты |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү | Дәүләт хезмәтеннән файдалануга гариза тапшырудан тыш, дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затлар регистрында үзләре турында белешмәләр булган эшсез гражданнарга телефон яки электрон элемтә чараларыннан файдаланып, өч календарь көне эчендә халыкның мәшгульлек үзәгенә килү тәкъдиме белән, эшсез гражданинның һөнәри әзерлек дәрәҗәсе хезмәт функциясен үтәү өчен эшкә алучы таләпләренә туры килү шарты белән, буш эш | 92н номерлы стандартның 6 пункты<br>92н номерлы стандартның 22 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | урыны (вакантлы вазыйфа) булуы турында эшкә алучыдан мәгълүматлар килүе турында мәгълүмат алу мөмкинлеге тудырыла.<br>Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар халыкның мәшгульлек үзәгенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук эшсез гражданин тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә электрон саклагычлардан файдаланып та тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль законда һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның 21[1] статьясы һәм 21[2] статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.<br>Гариза һәм гариза бирүченең гаилә әгъзаларының яки аларның законлы вәкилләренең үзләренең шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын раслый торган документ гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль законда һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның 21[1] статьясы һәм 21[2] статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.<br>Документларны (документларның күчермәләрен) электрон документлар формасында тапшырган очракта, әгәр алар 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның 21[1] һәм 21[2] статьялары таләпләре нигезендә һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән имзаланмаган | 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 21[1] һәм 21[2] статьялары»; |

| | | |
|---|---|---|
| | (таныкланмаган) булса,финанс ярдәме билгеләү гариза бирүче тарафыннан аларның төп нөсхәләре яки законнарда билгеләнгән тәртиптә кәгазьдә таныкланган күчермәләре халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырылганнан соң гамәлгә ашырыла. | |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәгечә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.4.2 пунктта:

3.4.2.1 пунктчада «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.4.2.2 пунктчанда «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.5.2 пунктта:

3.5.2.1 пунктчада «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.5.2.2 пунктчада «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.5.11 пунктта «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.6 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.7 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Административ регламентның 13 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.»;

өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

4.4 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«4.4. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә эшсез гражданнарның хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Гариза бирүчеләр судка кадәр тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи заты (белгече) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министр исеменә тапшырыла.

КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә белдерелә, КФҮ җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата – КФҮ гамәлгә куючыга.»;

5.7 пунктта «хезмәткәр» сүзен «халыкның мәшгульлек үзәге белгече» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек өстәргә:

«6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Гариза бирүче КФҮ мөрәҗәгать иткәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында гариза бирүчегә хәбәр итү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) халыкның мәшгульлек үзәгенә гаризаны җибәрү.

6.2. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен КФҮ шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече гариза бирүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны КФҮнең http://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алуның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.3.1. Гариза бирүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пункты нигезендә КФҮ, КФҮнең читтән торып эшләү урынына тапшыра.

6.3.2. КФҮнең гаризалар кабул итә торган белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар КФҮ эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. халыкның мәшгульлек үзәгенә гаризаны җибәрү.

КФҮ белгече гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибе - халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турында килешү белән, ә КФҮнең гариза

бирүчеләр белән хезмәттәшлек итү тәртибе КФҮ эш регламенты белән җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламентында, халыкның мәшгульлек үзәге белән КФҮ арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны КФҮдә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – халыкның мәшгульлек үзәгенә юлланган гариза.

6.5. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән бәяләмәдә хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турындагы гаризаны гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы заты аша КФҮгә язмача тапшыра.

КФҮнең гаризалар кабул итә торган белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.6. Халыкның мәшгульлек үзәгенә техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү.

КФҮ белгече халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны КФҮдә теркәгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.»;

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
халыкның мәшгульлек хезмәте
дәүләт учреждениеләре юлламасы
буенча эшкә урнашу өчен, эшсез
гражданнарга бер урыннан икенче
урынга күченүдә һәм эшсез
гражданнарга һәм аларның гаилә
әгъзаларына башка җирлеккә
күченеп урнашуда булышлык итү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 1 нче
кушымта

Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре

| Халыкнвың мәшгульлек үзәгенең аталышы | Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|---|
| «Азнакай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85592) 7-57-00 | Czn.Aznakaevo@tatar.ru |
| «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84344) 2-74-61 | Czn.Aksubaevo@tatar.ru |
| «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85552) 3-09-83 | Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| «Алексеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84341) 2-54-00 | Czn.Alekseevskoe@tatar.ru |
| «Әлки районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84346) 2-15-21 | Czn.Alkeevo@tatar.ru |
| «Әлмәт шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8553) 32-34-99 | Czn.Almet@tatar.ru |
| «Апас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84376) 2-12-15 | Czn.Apastovo@tatar.ru |
| «Арча районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84366) 3-29-33 | Centr.Arskiy@tatar.ru |
| «Әтнә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84369) 2-16-50 | Czn.Atnya@tatar.ru |
| «Баулы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85569) 5-27-10 | Czn.Bavly@tatar.ru |
| «Балтач районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84368) 2-52-34 | Czn.Baltasi@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Бөгелмә шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85594) 4-48-53 | Czn.Bugulma@tatar.ru |
| «Буа шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84374) 3-35-89 | Czn.Buinsk@tatar.ru |
| «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84379) 2-18-99 | Czn.V-uslon@tatar.ru |
| «Биектау районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84365) 2-16-17 | CZN.VGora@tatar.ru |
| «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84375) 2-24-51 | Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| «Алабуга шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85557) 7-58-58 | Czn.Elabugi@tatar.ru |
| «Зәй шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85558) 3-18-92 | Czn.Zainsk@tatar.ru |
| «Зеленодольск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84371) 5-64-90 | Czn.Zdol@tatar.ru |
| «Кайбыч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84370) 2-10-06 | Czn.Kaybicy@tatar.ru |
| «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84364) 2-67-54 | Czn.Kukmor@tatar.ru |
| «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84378) 2-48-12 | Laish.Czn@tatar.ru |
| «Лениногорск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85595) 5-10-40 | Czn.Leninogorsk@tatar.ru |
| «Мамадыш районы | директор | (85563) | Czn.Mamadysh@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | | 3-35-57 | |
| «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Әгерже районы филиалы | директор | (85549) 2-02-02 | Czn.Men@tatar.ru |
| «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85555) 3-23-80 | Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| «Мөслим районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85556) 2-49-50 | Czn.Muslymovo@tatar.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Тукай районы филиалы | директор | (8552) 52-46-99 | Chelny.CZN@tatar.ru |
| «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Аланы бүлеге | директор | (8555) 42-40-79 | Czn.Nk@tatar.ru |
| «Яңа Чишмә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84348) 2-30-42 | Czn.Novoshesh@tatar.ru |
| «Нурлат ш. халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84345) 2-46-32 | Czn.Nurlat@tatar.ru |
| «Питрәч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84367) 3-04-84 | CentrZan.Pestr@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Балык Бистәсе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84361) 2-21-81 | Czn.R.sloboda@tatar.ru |
| «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84362) 2-28-15 | SZN.Saby@tatar.ru |
| «Сарман районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85559) 2-42-62 | Czn.Sarmanovo@tatar.ru |
| «Спас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84347) 3-07-72 | Czn.Bolgar@tatar.ru |
| «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Тамагы районы филиалы | директор | (84373) 2-63-29 | Czn.Tetyushi@tatar.ru |
| «Теләче районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84360) 2-12-68 | Czn.Tyulyachi@tatar.ru |
| «Чирмешән районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84396) 2-54-59 | Czn.Cheremshan@tatar.ru |
| «Чистай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84342) 5-30-61 | Czn.chist@tatar.ru |
| «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85593) 2-98-00 | Czn.Yutazy@tatar.ru |
| «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Совет районы филиалы | директор | 562-48-33 | Czn.g Kazan@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Авиатөзелеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | 537-86-00 | Czn.Avia@tatar.ru |
| «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | 277-40-42 | Czn.Vah@tatar.ru |
| «Киров районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | 554-77-74 | czn.kirovskiy@tatar.ru |
| «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | 564-58-72 | czn.moskovski@tatar.ru |
| «Яңа Савин районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | 560-26-95 | Czn.Novosavin@tatar.ru |
| «Идел буе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | 224-86-83 | CZN.Privol@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-03 | Klara.Tazetdinova@tatar.ru |
| Хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы | 557-21-58 | Azat.Ayupov@tatar.ru»; |

5 нче кушымтада «2.9 пункт» сүзләрен «2.8 пункт» сүзләренә алмаштырырга.